ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 23 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9, № 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1 – 2, № 5, № 6 (I өлеш), № 7, № 12 (III өлеш); 2015, № 3, № 4, № 12 (I өлеш); 2016, № 5, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 85 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 2.17 статья өстәргә:

«2.17 статья. **Яңа коронавирус инфекциясе (COVID-19) таралуны кисәтүгә һәм аның зыяннарын бетерүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары таләпләрен үтәмәү**

1. Яңа коронавирус инфекциясе (COVID-19) таралуны кисәтүгә һәм аның зыяннарын бетерүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары таләпләрен үтәмәгән өчен, әгәр дә мондый гамәлләрдә (гамәл кылмауларда) җинаять җаваплылыгы гамәлләре булмаса яисә алар Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы нигезендә административ җаваплылыкка китермәсә, –

кисәтү ясала яисә гражданнарга – бер меңнән алып дүрт мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – унбиш меңнән алып кырык мең сумга кадәр; юридик затларга ике йөз меңнән алып өч йөз мең сумга кадәр административ штраф салына.

2. Шул ук гамәлләрне кабат кылган өчен –

гражданнарга – биш мең сум; вазыйфаи затларга – кырык меңнән алып илле мең сумга кадәр; юридик затларга өч йөз меңнән алып биш йөз мең сумга кадәр административ штраф салына.»;

2) 7.1 статьяда «2.11 – 2.16» саннарын «2.11 – 2.17» саннарына алмаштырырга;

3) 8.1 статьяның 14 өлешендә «2.16,» саннарыннан соң «2.17,» саннарын өстәргә.

**2 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясында (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 7 (II өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 7; 2015, № 3, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 79 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш) «2.16,» саннарыннан соң «2.17,» саннарын өстәргә.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2020 ел, 24 апрель
№ 17-ТРЗ